КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 апрель г.Казань № 286

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру өстенлекле проектын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 706 нчы карары белән расланган Төзекләндерелергә тиешле иҗтимагый территорияләрне сайлап алу буенча тавыш бирүне оештыру һәм үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру өстенлекле проектын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 706 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 сентябрь, 706 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Төзекләндерелергә тиешле иҗтимагый территорияләрне сайлап алу буенча тавыш бирүне оештыру һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Иҗтимагый территорияне Программага кертү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге (муниципаль район, шәһәр округы) башкарма комитеты тарафыннан (килешү буенча) иҗтимагый территориянең урнашу урыны буенча (алга таба – Башкарма комитет) кабул ителә. Әлеге тәкъдимнәр ел саен 10 гыйнвардан 8 февральгә кадәр кабул ителә.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Башкарма комитетның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында тиешле исемлеккә кертелгән җәмәгать территорияләрен төзекләндерү буенча проект тәкъдимнәре (дизайн-проектлар) әзерләү һәм урнаштыру, кызыксынган барлык затларны аның белән таныштыру максатларында, ел саен 1 марттан да соңга калмыйча 15 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

5.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан эшләнгән «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» федераль проекты кысаларында иҗтимагый территорияләрне сайлап алу буенча тавыш бирүне уздырганда Иҗтимагый комиссия рейтинг тавыш бирүне оештыруның аерым мәсьәләләре буенча тәкъдимнәргә таяна.»;

6.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый территорияләрне сайлап алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар Башкарма комитетның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында рәсми басылып чыгарга тиеш.

Иҗтимагый территорияләрне сайлап алу буенча тавыш бирүне үткәрү белән бәйле документлар, шул исәптән исемлекләр, сораштыру кәгазьләре, беркетмә Башкарма комитетта бер ел дәвамында саклана, аннары юкка чыгарыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.11 пункт өстәргә:

«6.11. Иҗтимагый территорияләрне сайлап алу буенча тавыш бирү үткәрү чараларын исәпкә алуны оештыру максатларында Башкарма комитетлар ел саен 15 гыйнвардан 15 апрельгә кадәр айга ике тапкыр (10 һәм 25 числоларда) иьтимагый территорияләрне сайлап алу буенча тавыш бирүне үткәрү турында Министрлыкка хисап җибәрә.

Иҗтимагый территорияләрне сайлап алу буенча тавыш бирү тәмамлану турында хисап, тавыш бирүчеләр санын күрсәтеп, тавышларны тавыш бирү территорияләре бүлеп, Башкарма комитетлар тарафыннан ел саен 15 апрельгә кадәр Министрлыкка җибәрелә».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин